| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.09.2022 ел Олы Кайбыч ав. № 138

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2022 елның 24 маендагы 122 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече Кузьмина Алсинә Ирек кызын балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе җаваплы секретаре итеп;

ГАУСО «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өмет» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» Социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе директоры Нигъмәтҗанова Гөлия Насыйх кызын комиссия әгъзасы итеп комиссия составына кертергә;

Макарова Алена Сергеевнаны комиссия составыннан төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Рәис А.И.Рәхмәтуллин